Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы

КАРАР

22 ноябрь 2023 ел

№28

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 1 өлешендәге 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«12) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

1.2. түбәндәге эчтәлектәге 18.1 статьясы белән тулыландырырга:
«18.1 статья Авыл җирлеге старостасы
1. Җирле үзидарә органнары һәм авыл торак пункты халкының җирлектә урнашкан авыл торак пунктында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә үзара хезмәттәшлекне оештыру өчен, авыл җирлеге старостасы билгеләнергә мөмкин.
2. Авыл торак пункты старостасы составына әлеге авыл торак пункты кергән авыл җирлеге Советы тарафыннан авыл торак пункты гражданнары җыены тәкъдиме буенча билгеләнә. Авыл торак пункты старостасы әлеге авыл торак пункты территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары арасыннан яисә гражданнар җыены тәкъдим иткән көнне 18 яшькә җиткән һәм әлеге авыл торак пункты территориясендә урнашкан торак бинасы булган Россия Федерациясе гражданнары арасыннан билгеләнә.
3. Авыл торак пункты старостасы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш, дәүләт вазыйфасын, дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын алмаштыручы зат булмый, хезмәт мөнәсәбәтләрендә һәм җирле үзидарә органнары белән турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрдә була алмый.
Татарстан Республикасы законы белән тарихи һәм башка җирле традицияләрне исәпкә алып, авыл җирлеге старосты вазыйфасының башка атамасы билгеләнергә мөмкин.
4. Авыл җирлеге старостасы итеп түбәндәге зат билгеләнә алмый:
1) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш, дәүләт вазыйфасын, дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын алмаштыручы;

2) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган;

3) гамәлдән чыгарылмаган яки төшерелмәгән хөкем ителүе булган.

5. Авыл торак пункты старостасының вәкаләтләре 5 ел тәшкил итә. Авыл җирлеге старостасының вәкаләтләре авыл торак пункты гражданнары җыены тәкъдиме буенча составына әлеге авыл торак пункты кергән авыл җирлеге Советы карары буенча, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясының 10 өлешендәге 1 7 пунктларында билгеләнгән очракларда.вакытыннан алда туктатыла.

6. Авыл җирлеге старостасы аңа йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен түбәндәгеләрне башкара:

1) авыл торак пунктында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлек итә;

2) халык белән хезмәттәшлек итә, шул исәптән гражданнар җыеннарында, җыелышларында, конференцияләрендә катнашу аша, мондый чаралар нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри каралырга тиешле муниципаль хокукый актлар проектлары рәвешендә рәсмиләштерелгән мөрәҗәгатьләр һәм тәкъдимнәр җибәрә;

3) авыл торак пунктында яшәүчеләргә җирле үзидарә оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирә, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан алынган башка мәгълүматны аларга җиткерүдә ярдәм итә;

4) җирле үзидарә органнарына гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларын оештыруда һәм үткәрүдә, аларның нәтиҗәләрен авыл җирлегендә игълан итүдә ярдәм итә;

5) авыл җирлеге халкы өчен өстенлекле әһәмияткә ия булган мәсьәләләр буенча инициатив проект кертү инициативасы белән чыгыш ясау хокукына ия;

6) әлеге Устав һәм (яки) Татарстан Республикасы Законы нигезендә җирлек Советының норматив хокукый актында каралган башка вәкаләтләрне һәм хокукларны гамәлгә ашыра.

7. Авыл торак пункты старостасының эшчәнлеге гарантияләре һәм статусының башка мәсьәләләре әлеге Устав һәм (яки) Татарстан Республикасы Законы нигезендә авыл җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

1.3. 30 нчы статьяга түбәндәге эчтәлекле 9 нчы өлешне өстәргә:

«9. Җирлек Советы депутаты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгәне һәм бурычларны үтәмәгәне өчен, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү күрсәтелгән затлардан бәйсез булган хәлләр тикшерүе тарафыннан «Ришвәтчелеккә каршы тору турында»2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә таныла икән ришвәтчелеккә каршы тору максатында җаваплылыктан азат ителә.»;

1.4. 40 нчы статьяга түбәндәге эчтәлекле 2.1 өлешен өстәргә:

«2.1. Район җирлеге депутатының вәкаләтләре район җирлеге карары белән, әгәр депутат җитди сәбәпләрсез район җирлегенең барлык утырышларында алты ай рәттән катнашмаса, вакытыннан алда туктатыла.»;

1.5. 43 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 нчы өлешне өстәргә:

«6. Җирлек башлыгы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгәне һәм бурычларны үтәмәгәне өчен, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү ажардан бәйсез булган хәлләр тикшерүе тарафыннан «Ришвәтчелеккә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль

законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә таныла икән ришвәтчелеккә каршы тору максатында җаваплылыктан азат ителә.»;

1.6. 49 статьяның 1 өлеше 9 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшли һәм гамәлгә ашыра, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

1.7. 63 статьяда:

а) 1 нче өлештә:

1 нче пунктны «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

2 пунктта «яки белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматны тәкъдим итү» сүзләрен «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган мәгълүмат тапшыру яки белә торып дөрес булмаган мәгълүмат тапшыру» сүзләренә алыштырырга;

б) 2 нче өлешне «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

1.8. 71 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«71 статья. Муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (игълан итү) һәм аларның үз көченә керү тәртибе

1. Муниципаль хокукый актлар, җирлек Советының Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә торган Салымнар һәм җыемнар турында норматив хокукый актларыннан тыш, имзаланганнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Җирлек башлыгының, җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларының хокукый актлары, әгәр шул ук актлар белән башкасы билгеләнмәгән булса, алар имзаланган көннән үз көченә керә.

3. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, муниципаль берәмлек оештыручы булып торган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Муниципаль хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне игълан итү дип түбәндәгеләр таныла:

1) муниципаль хокукый актны рәсми рәвештә бастырып чыгару;

2) муниципаль хокукый актны чикләнмәгән затлар (дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль китапханәләр, файдалана алырлык башка урыннарда) файдалана алырлык урыннарда урнаштыру;

3) хокукый акт текстын җирлек торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру. Күрсәтелгән стендларның саны һәм аларның урнашу урыннары җирлек Советы тарафыннан раслана һәм җирлек халкы тарафыннан муниципаль хокукый акт тексты белән каршылыксыз танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш;

4) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштыру;

5) Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресында урнаштыру (ЭЛ ММЧ ны теркәү турында ФС 77 – 602 номерлы таныклык 44 2014 елның 17 декабрендә Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән).

5. Муниципаль хокукый актның, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең рәсми басылышы булып аның тулы текстының «Хезмәт даны» («Трудовая слава») газетасында беренче басылуы яки аның тулы текстының Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында беренче урнаштырылуы санала.

6. Әгәр муниципаль хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә бастырып чыгару челтәр басмасында икән, җирлектә 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматка керүне тәэмин итү турында» Федераль закон нигезендә җирлектә, өстәмә техник чаралар кулланмыйча гына, чикләнмәгән төркем кешеләр файдалана алырлык урыннарда дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль китапханәләр, файдалана алырлык башка урыннарда) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренә тоташтыруның бер яки берничә пунктын булдыру тәэмин ителә.

7. Һәр муниципаль хокукый актта аның реквизитлары булырга тиеш: аның исеме, имзалау датасы (җирлек Советы кабул иткән хокукый актлар өчен – шулай ук җирлек Советы аны кабул иткән дата), теркәлү номеры, хокукый актка кул куйган вазыйфаи затның исеме, мөһере.

8. Җирлек Советының җирлек бюджеты турында, аның үтәлеше турында хисап турында, җирле салымнар һәм җыемнар билгеләү турында карарлары, җирлек Советы Регламенты, җирлек Советы, җирлек Башлыгы тарафыннан кабул ителгән башка норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр, таралуы федераль закон белән чикләнгән мәгълүматлары булган муниципаль хокукый актлардан яки аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, алар имзаланганнан соң җиде көн эчендә рәсми рәвештә бастырылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

9. Муниципаль сайлаулар, җирле референдум билгеләү турында, җирлек Советы депутатының вәкаләтен туктату, чикләрне үзгәртү, җирлекне үзгәртеп кору, җирлек Башлыгын һәм аның урынбасарын сайлау мәсьәләсе буенча тавыш бирүне билгеләү турында норматив булмаган хокукый актлар һәм закон нигезендә башка актлар мәҗбүри рәвештә рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

10. Закон яки әлеге Устав нигезендә рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка игълан итү) мәҗбүри булмаган норматив булмаган муниципаль хокукый актлар аларны чыгарган җирле үзидарә органнары яки вазыйфаи затлары карары буенча бастырылырга (халыкка игълан ителергә) мөмкин.

11. Бастырганда (халыкка игълан иткәндә) муниципаль хокукый актның реквизитлары күрсәтелә.

12. Муниципаль норматив хокукый актлар, шул исәптән җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән карарлар оештыру һәм алып бару Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертелергә тиеш.»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авылы территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы: Ф.М.Фаттахов

ОГРН 1021607753232
ИНН 1623001727